УДК 398.3

***И.И. Фазлетдинов***

# БАШКОРТСТАНДАГЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНА НИГЕЗ САЛЫНУ ТУРЫНДАГЫ РИВАЯТЬЛӘР: ТАРИХИ АСПЕКТ

Статья посвящена исследованию исторических основ преданий о возникновении татарских сел и деревень Башкортостана, их взаимосвязи с социально-политическими процессами, протекающими в описываемые периоды. Отдельно выделяются и анализируются мотивы, связанные с насильственным крещением казанских татар Иваном Грозным, с освоением татарами-переселенцами новых земель, их взаимоотношениями с местным населением, языковой и религиозной самобытностью. Автор приходит к выводу о том, что произведения данной тематической группы являются художественным отражением реальной истории народа через призму фольклорного восприятия.

**Ключевые слова:** татарский фольклор, исторические предания, классификация, мотив, разновидности, исторический аспект, села Башкортостана.

The article is devoted to the study of the historical foundations of the traditions about the origin of Tatar villages of Bashkortostan, their relationship with the socio-political processes taking place in the described periods. The motives associated with the forced baptism of Kazan Tatars by Ivan the Terrible, with the development of new lands by the Tatar settlers, their relationship with the local population, linguistic and religious identity are separately highlighted and analyzed. The author comes to the conclusion that the works of this thematic group are an artistic reflection of the real history of the people through the prism of folklore perception.

**Keywords:** tatar folklore, historical traditions, classification, motive, varieties, historical aspect, villages of Bashkortostan.

Татар халкының авыл тарихларына багышланган риваятьләрен җыю һәм өйрәнү тарихы артык зур түгел. XX гасырның соңгы чирегенә кадәр ул фрагментар характерда була һәм вакытлы матбугатта дөнья күргән берничә мәкалә белән генә чикләнә. Системалы һәм шактый тулы рәвештә әлеге төркемгә караган риваятьләр беренче тапкыр 1987 елда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» 12 томлыгының «Риваятьләр һәм легендалар» томында урын ала [Татар халык..., 1987, б. 137–204]. Биредә 94 авыл тарихы урнаштырыла, шуларның 13е Башкортстандагы татарлар күпләп яшәгән районнарда язып алына [Татар халык..., 1987, б. 137–204].

Башкортстан татарларының фольклорын, аерым алганда, риваятьләрен һәм легендаларын җыю һәм өйрәнү тарихы күренекле галим Р.М. Мөхәммәтҗанов тарафыннан 1960 еллар урталарыннан гына башлана. Ул 1962–1990 елларда Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы доценты сыйфатында республикадагы 150 дән артык татар авылын фольклор экспедицияләре белән

урап чыгып, бай материал туплый; аларны саклау һәм өйрәнү өчен кафедра каршында махсус фольклор фонды оештыра [Фазлетдинов, 2019, б. 95–96]. Тупланмада риваятьләр һәм легендалар, шул исәптән, авыл тарихларына багышланганнары да, шактый күп була, ләкин алар үз вакытында басылып чыкмый һәм фәнни тикшерү объекты буларак каралмый [Фазлетдинов, 2019, б. 96].

Р.М. Мөхәммәтҗановның 1995 елда вакытсыз вафатыннан соң бу эш аның укучысы И.К. Фазлетдинов тарафыннан дәвам иттерелә. Башкортстан татарларының риваятьләр һәм легендалар мирасын өйрәнү буенча махсуслашып, ул 2005 елда «Башкортстан татарларының топонимик риваятьләре һәм легендалары: тарихи нигезләре һәм идея-эстетик функцияләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый [Фазлутдинов, 2005]. Хезмәтнең бер бүлегендә авыл атамаларына бәйле этиологик мотивларның риваять сюжетындагы урыны тикшерелә. [Фазлутдинов, 2005, с. 106–173]. Моннан тыш яшь галим Башкортстандагы авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә XVI–XIX гасырлардагы миграция процессларының чагылышын анализлаган монографик пландагы тикшеренүен бастырып чыгара [Фазлетдинов, 2003, 201 б.]. Аның кушымтасында 173 риваять тексты урын ала [Фазлетдинов, 2003, б. 112–184]. Нигездә, үзе туплаган материалларга нигезләнеп, И.К. Фазлетдинов 2018 елда Башкортстан китап нәшриятында «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» китабын нәшер итә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр..., 2018]. Биредә урын алган 702 фольклор үрнәгенең 169 ын авыл тарихлары турындагы риваятьләр тәшкил итә [Башкортстан..., 2018, б. 37–105]. Остазы Р.М. Мөхәммәтҗанов туплаган материалларны электрон форматка күчереп һәм шуңа үзе җыйган язмаларны өстәп, И.К. Фазлетдинов 2021 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать интитутында өч китаптан торган «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясен бастырып чыгара [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021]. Тарихи-географик принциптан чыгып төзелгән җыентыкларга башка фольклор жанрлары белән беррәттән 167 авыл тарихы тексты да урнаштырыла [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 23–46; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 23–60; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 23–61]. Әлеге язмабызның тикшеренү объекты булып әлеге тупланмаларда нәшер ителгән авыл тарихлары турындагы риваятьләр һәм үзебез туплаган аерым материаллар, тарихи чыганаклар хезмәт итә.

Риваятьләр составындагы авыл тарихлары – бик үзенчәлекле төркем. С.М. Гыйләҗетдинов билгеләвенчә, алар «гадәттә, теге яки бу авылның кайдан, кайчан, нинди сәбәпләр аркасында күчеп килүе турында сөйли. Авыл тарихларында төбәккә беренче килеп утыр-

ган кешеләр, аерым нәселләр тормышындагы мөһим вакыйгалар турында төрле мәгълүматлар бирелә. Бу ягы белән алар тарихи риваятьләргә якын торалар. Күп әсәрләрдә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. Монысы исә – топонимик риваятьләргә хас күренеш» [Гыйләҗетдинов, 1987, б. 13]. И.К. Фазлетдинов фикеренчә, «авыл тарихларының шушы үзенчәлеге – бер үк вакытта топонимик та, тарихи да характерга ия булуы – аларны риваятьләр составындагы аерым төркем итеп карарга мөмкинлек бирә» [Фазлетдинов, Кереш, 2021, б. 16]. Шуны истә тотып, автор үзе төзегән җыентыкларда әлеге төркемне топонимик риваятьләргә дә, тарихи риваятьләргә дә кертмичә, аерым урнаштыра.

Н.А. Криничная рус халкының тарихи риваятьләрен 9 тематик төркемгә бүлеп анализлый. Галимә аерып чыгарган беренче сюжет төркеме – аерым бер төбәккә урнашу (күченү) һәм аны үзләштерү турындагы әсәрләр.

Калганнары – төбәкнең борынгы халкы – «аборигеннары»; «паннар» – алпавытлар; яшерен хәзинәләр; алып, батыр, пәһлеваннар; илбасарлар белән көрәш; караклар һәм юлбасарлар; патриарх Никон реформалары белән килешмичә, православие диненең борынгы рәвешенә тугры калган раскольниклар һәм тарихи затларга бәйле риваятьләр [Криничная, 1987, с. 30–220].

Әлеге классификациягә таянып, бу мәкаләдә без беренче сюжет төркеменә караган риваятьләрне тикшерәбез. Аерым бер төбәккә күченеп урнашу һәм аны үзләштерүгә багышланган әсәрләр Башкортстан татарлары риваятьләре составында иң еш очрый торганы һәм ул шактый архаик төркемне тәшкил итә.

Бу сюжет төркемен түбәндәге мотивлар барлыкка китерә.

1. Авылга нигез салучы аерым бер кеше турындагы әсәрләр. Мәсәлән, Куергазы районының Тимербай, Кушнаренко районының Иске Тукмаклы, Кыйгы районының Идрис, Султановка, Мәчетле районының Абдулла, Тәтешле районының Аксәет, Туймазы районындагы Карамалы-Гобәй, Мулла, Тукай, Ярмөхәммәт авыллары тарихларына багышланган риваятьләр [Башкортстан…, 2018, б. 69–70, 71, 74, 75; Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 31–32, 34, 36–37, 37–38; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 42–43, 47].

2. Авылга нигез салучы бертуганнар турындагы үрнәкләр. Мәсәлән, Кушнаренко районының Рәсмәкәй, Туймазы районының Сәрдек, Ярмәкәй районының Сөярмәт авылларына багышланган риваятьләр [Башкортстан…, 2018, б. 72; Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 35, 44–45].

3. Конкрет территориядән тулы гаилә белән күчеп утыру хакындагы әсәрләр. Мәсәлән, Краснокама районының Яңа Каенлык, Кушнаренко районының Әхмәт авыллары тарихлары [Башкортстан…, 2018, б. 70; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 37–38].

4. Авыллары белән күченүчеләр яки туганлык мөнәсәбәтләрендә торучы халыкның төркем белән яңа җирләргә килеп төпләнүе турындагы үрнәкләр. Мәсәлән, Краснокама районының Яңа Хаҗи, Кушнаренко районының Үгез, Кыйгы районының Йөрәкле, Майский, Тукай, Мәчетле районының Яңа Мөслим авыллары тарихлары [Башкортстан…, 2018, б. 74, 75; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 38, 40, 44–45].

И.К. Фазлетдинов Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаучы риваятьләрдәге авыл атамасының барлыкка килү мотивлары әлеге версияләргә генә сыешып бетми, дип билгели [Фазлетдинов, 2021, б. 85].

Аерым вакыйгаларга мөнәсәбәттә барлыкка килгән авыл исемнәре турындагы риваятьләрне дә галим яңа төркем буларак күрсәтә. Авыл атамалары, үз чиратында, тарихи вакыйгалар яки шәхесләр турындагы мәгълүматларны гына түгел, халыкның анимистик һәм тотемистик карашларын, борынгы ышануларын да саклый [Фазлетдинов, 2021, б. 85].

Башкорт фольклорчысы Ф.А. Нәдершина үзенең хезмәтләрендә авылларның килеп чыгышына бәйле тагын берничә мотивка туктала: нәсел башлыгының ничә бала үстерүе һәм нәселнең кайларда төпләнүе; беренче урнашкан кешеләрнең ыру-кабилә мөнәсәбәтләре; төбәккә башка милләт вәкилләренең күчеп утыруы; авыл янында аерым бер таш яисә корылма (ныгытма) хасил булу; күчеп утыручыларның балаларга үзенчәлекле исем кушулары; авыл атамасының көндәлек тормышта булган хәл белән аңлатылуы; кайчандыр әйтелгән сүзләргә бәйле мотивлар [Нәҙершина, 2006, б. 152–234].

Татарларның Россиянең төрле төбәкләренә һәм чит илләргә күчеп китүенең сәбәпләре, нигездә, тарихи шартлар белән бәйле. Бу – беренче чиратта, төрле сугышлар вакытында йорт-җирсез калу, басып алучылардан качып котылырга омтылу, җир җитмәү, ачлык. Татар халкына бәйле күченүләрнең тагын бер сәбәбе – халыкның үз динендә калырга теләве, ягъни көчләп чукындырулардан качу. Бу вакыйгалар язма чыганакларда, тарихи риваятьләрдә, шактый шартлы гына булса да, дастаннарда да саклана. Тарихи характердагы матур әдәбиятта да әлеге вакыйгаларга карата мәгълүматлар очрый.

Башкортстан татарларының аерым авылларына нигез салыну, аларның монда килеп урнашуы турындагы мәгълүматлар Әмирхан Еникиның «Соңгы китап» әсәрендә теркәлгән. Автор документаль характердагы әлеге әсәрендә үз нәселенең, ата-бабаларының һәм гомумән төмән кабиләсенең (хәзерге Мордовия Республикасы Темников шәһәре халкы) Башкортстан җиренә урнашу тарихын киң яктырта, тарихын һәм үткәнен ачыклый [Еники, 1987, б. 4–12].

Халык хәтеренең билгеле бер чикләре бар. Белгечләр риваять-легендаларның халык хәтерендә 200–500 ел чамасы саклануын әйтәләр, язмача теркәлмәгән очракта бу әсәрләр күпмедер вакыт үткәннән соң онытылуга дучар була [Толстова, 1983, с. 6–21]. Мәсәлән,

Аксак Тимер басып алулары, шул чорда күчеп килгән авыллар турында тарихи риваятьләр XX гасырда бик сирәк очрый. Бу, бер яктан, халык хәтеренең үз закончалыклары белән бәйле булса, икенче яктан, аларны соңрак булган вакыйгалар кысрыклап чыгара. Аксак Тимернең басып алу сугышларына бәйле вакыйгалар Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы турындагы риваятьләргә күчерелә. Бу – фольклорга хас анахронизм күренеше булып тора. Шулай итеп, бер риваятьтә берничә тарихи катлам яшәвен дә күзәтергә мөмкин.

Моның ачык чагылышын Башкортстандагы татар авыллары тарихларына багышланган риваятьләрдән дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, биредә язып алынган үрнәкләрнең зур өлешендә Казан ханлыгы һәм Сембер губернасында яшәүче татарларның хәзерге Башкортстан җирләренә күчеп утыруы Явыз Иванның басып алу сәясәте, дөресрәге, аның яулап алу сугышларына бәйләп аңлатыла.

Мәсәлән, БДУ студенты Алсу Сөнәгатуллина тарафыннан укытучы Байсар Иманголовтан язып алынган Туймазы районы Карамалы-Гобәй авылы тарихының бер вариантын алып карыйк. «Элгәре Иван Грозный исемле бик явыз патша була. Ул башта мордва халкын басып ала, аннан чират чуваш, марилларга да җитә. Моннан соң Иван патша Урта Идел буенда яшәүче болгарларны да басып алмакчы була һәм Казанга һөҗүм итә. Ул Казанны ала алмый һәм ачуыннан тирә-яктагы авылларны туздыра. Шундый авылларның берсе – безнең ата-бабаларыбыз яшәгән Байлар Сердәге исемле авыл була.

Бу авылда Гобәй исемле мулла яшәгән. Ул бик акыллы булган һәм халык аны нык ихтирам иткән. Урыс гаскәрләре килә башлагач, ул авыл халкын өлкән улы җитәкчелегендә Уралга озата. Тик үзе туган төягеннән китми, берничә авыл карты белән шунда кала. Сатлыкҗаннар аны урыс гаскәрләренә тотып бирәләр. Урыслар казанда сумала кайнатып, шунда Гобәйне салып үтерәләр. Калган картларны коллыкка озаталар.

Мулланың өлкән улы Алдаргол авыл халкын башкорт җирләренә алып бара. Алар Өсән елгасының аръягында тукталалар һәм әлеге Алдар тавында төпләнәләр. Яңа авылга Гобәй мулла исемен кушалар. Авылның тирә-ягын карама урманы әйләндереп алганлыктан, тиздән ул Карамалы-Гобәй дип атала башлый...» [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 31–32].

И.К. Фазлетдинов билгеләвенчә, бу авыл тамырлары белән хәзерге Татарстанның Кукмара районында урнашкан Зур Сәрдек авылына килеп тоташырга тиеш. 1994 елда Кукмара районында телче-галим Дөрия Рамазанова язып алган Сәрдекбаш авылы тарихына нигезләнеп, ул Зур Сәрдек авылын да читтән килүчеләр – хәзерге Киров өлкәсе Малмыж районындагы Старый Бурец авылыннан кайчандыр күчеп утыручылар нигезләвен исбатлый. Шулай итеп, «бер-берсеннән йөзләрчә чакрым читтә урнашкан һәм Россиянең өч төбәгенә караган авылларның тамырлары уртак булып чыга», дип фаразлый галим [Фазлетдинов, 2022, 21 окт.]. Без исә бу мәсьәләдә үз версиябезне

тәкъдим итәбез. Башкортстанның Туймазы районындагы Карамалы-Гобәй авылы, чынлыкта, Татарстанның Балтач районына караган Байлар Сәрдеге (рус. Бурбашский Сардыган) авылыннан күчеп килүчеләр тарафыннан нигезләнгән булырга тиеш. Бу авыл шулай ук заманында Казан губернасының Арча кантонына карый [Бөрбаш Сәрдегәне авылы тарихы]. Риваятьтә авыл атамасындагы «Сәрдек» сүзенең «Сердәк» булып үзгәрүен без гасырлар дәвамында барган фонетик процесслар, риваятьче хәтерендә күп кенә тарихи фактларның конкретлыгын югалта баруы белән аңлатабыз.

Бер үк вакытта нәкъ шушы риваять төрле чорларга караган тарихи катламнарның бер текст эчендә берегеп килүенә дә мисал була ала.

Шунысын да әйтеп үтү кирәк: күп кенә язма истәлекләр раслаганча, Башкортстанда татарлар Алтын Урда заманында ук яшәгән [Гильом де Рубрук..., с. 343]. Шуңа күрә, «Уфа татарлары» термины Идел буеннан Агыйделгә кадәрге территориядә элек-электән полоса булып сузылган татар авыллары утыруы аркасында кулланылышка кереп китмәгән [Миргалеев, Аксанов..., 2016, с. 6], чөнки биредә татарлар Уфа кальгасы барлыкка килгәнче үк (ягъни 1574 елга кадәр) яшәгән булып чыга.

«Фольклорда нәкъ менә шушы чорга кагылышлы, ягъни Казан яулап алынганнан соң Казан татарларының хәзерге Башкортстан территориясенә күчеп утыруларына бәйле ядкярләрнең аеруча күп сакланганлыгы тарих турында берьяклы нәтиҗәләр ясар өчен нигез була алмый, әлбәттә, – дип билгели филология фәннәре докторы Л.Х. Мөхәммәтҗанова. – Монда эпик характердагы фаҗигалы вакыйгаларның халык хәтеренә нык сеңеп, озак дулкынландырган булу фактын истән чыгарырга ярамый. Казан ягыннан килеп утырган татарларның Урал итәгендәге җирләргә урнашу вакыйгалары бу төбәккә татар кавеменең беренче кат аяк басуы дигән сүз түгел» [Мөхәммәтҗанова, 2019, б. 160–170]. И.К. Фазлетдинов фикеренчә, төбәктә язып алынган риваятьләрдә, шул исәптән, авыл тарихларында да, архаик, тамырлары белән борынгы мифологиягә килеп тоташкан мотивларның күп очравы да бу фаразның дөрес булуына ишарәли. Моңа мисал итеп, автор авылларны нигезләгәндә җирне тотем җанвар бүләк итү, яңа урында «изге» теләкнең тормышка ашуы, «илаһи билге» кебек мотивларны китерә һәм авыл тарихлары турындагы риваятьләрдә борынгы мал культы, тимерне изгеләштерү кебек бик ерак дәверләргә нисбәтле күренешләрнең образлы чагылышын билгели [Фазлутдинов, Синтез... 2021, с. 303–307]. Хәтта, беренче карашка, реаль эчтәлекле караклар һәм качкыннар турындагы риваятьләрдә дә мифологик карашлар бик зур роль уйный. Аерым алганда, биредә, «изгелекле» карак образларына мифик алыпларга хас сыйфатлар күчерелә [Фазлетдинов, Башкортстан татарларының качкыннар..., 2022, б. 88–89].

Авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрне анализласак, бер кызыклы күзәтү ясарга мөмкин: XVIII гасыр уртасы – XX гасыр

башында Башкортстан җирләрендә хасил булган татар авылларының күпчелеге эчке миграция, ягъни шушында ук элек нигезләнгән авыллардан халыкның бер өлеше күчеп китеп, яңа урыннарга барып төпләнүе нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Моның бер сәбәбе итеп, патшабикә Анна Иоанновна 1736 елның 11 февралендә кабул иткән Указны да исәпләргә мөмкин. Ул «дворяннарга, офицерларга, мишәрләргә» һәм шулай ук «типтәрләргә, бобыльләргә» башкорт җирләрен чикләүсез сатып алырга рөхсәт итә. Бу документ эчке миграция дулкыны көчәюгә зур этәргеч булган, дип исәпләргә тулы нигез бар. Моннан тыш XX гасыр башында крестьяннарны авыл общинасыннан тартып чыгарып, Европа илләре үрнәгендә аерым хуҗалыклар төзү максатын куйган Столыпин реформаларының да моңа тәэсире зур булган.

Риваятьләрдән күренгәнчә, татарларның элек килеп төпләнгән урыннарын ташлап, яңа җирләрдә авыл хасил итеп утыруларының төп сәбәбен табигый үсеш һәм Идел буеннан яңа күчеп килүчеләр өстәлү нәтиҗәсендә, халык саны артып, иске урында яшәү, иген игү өчен җир җитми башлау тәшкил итә. Билгеле, халыкның бер өлеше тормыш көтәр өчен яңа урыннар эзләргә мәҗбүр ителә. Мәсәлән, Зилаер районы Чуенчы-Чупан авылын Әлшәй районы Чуенчы авылыннан күчеп килгән татарлар 1901 елда Чупан нәселендәге башкорт байларыннан сатып алынган җирләрдә барлыкка китерәләр [Башкортстан…, 2018, б. 52–54].

Гомумән, риваятьләр өчен шундый бер мотив хас: авыл халкының бер өлеше, бүленеп, икенче урынга күчеп утырып, яңа авыл хасил итсә, аңа атама биргәндә, «яңа» сүзе кулланыла. Ягъни, халык элек яшәгән урынының исемен алып, аңа «яңа» сүзен өсти һәм, шул рәвешле, икенче атама хасил була. Бу эчке миграция күренешенең формаль күрсәткече булып хезмәт итә ала. Мәсәлән, авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә Кушнаренко районы Иске Тукмаклы авылыннан – шул ук районның Яңа Тукмаклы [Башкортстан…, 2018, б. 71], Илеш районы Иске Хаҗи авылыннан – Краснокама районы Яңа Хаҗи [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 38], Иглин районы Иске Юрмаш авылларыннан – шул ук районның Яңа Юрмаш [Башкортстан…, 2018, б. 54], Краснокама районы Бөртек авылыннан – шул ук районның Яңа Бөртек [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 36–37], күрше Каенлык авылларыннан – шул ук районның Яңа Каенлык [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 37–38], Илеш районы Иске Күктау авылларыннан – шул ук районның Яңа Күктау [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 45], Чакмагыш районы Карьяуды авылларыннан – шул ук районның Яңа Карьяуды [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 57–58] авыллары бүленеп чыгуы күрсәтелә.

Әгәр аерылып китүчеләр еракка күчеп утырсалар, аларның элек яшәгән урынnарының исеме турыдан-туры яңа урынга күчерелә. Мәсәлән, Ярмәкәй районы Сөярмәт авылы тарихында [Башкортстан

татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 42–44] аңа нигез салучыларның «Минзәлә аръягындагы Сөярмәт» исемле авылдан күчеп килүләре турында хәбәр ителә. Мәчетле районының Мөслим [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 44–45], Краснокама районының Яңа Кабан авыллары [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк..., 2021, б. 37] атамалары да җирле халыкның кайдан күчеп килгәнлегенә ишарә ясый[1].

Халыкның яңа нигезләгән авылга элек яшәгән урыннарының атамаларын бирүе очраклы түгел. Монда аның үз чыгышын, нәселнәсәбен ягъни тарихын, тамырларын саклап калырга омтылышы күренә. Киләчәк буыннар исем тәңгәллеге буенча, үзләренең бабаларының элек гомер иткән урыннарын тапсын, тамырларын онытмасын, аларның яшәү рәвешен, тормыш итү үзенчәлекләрен өйрәнсен өчен эшләнә бу эш. Ягъни биредә халкыбызның үзенчәлекле тормыш философиясе чагылыш таба.

Кайбер риваятьләрдә элек яшәгән урында төрле милләт, сословие, конфессия вәкилләре арасында низаглар чыгу Башкортстанда эчке миграция нәтиҗәсендә яңа авыллар барлыкка килүнең тагын бер сәбәбе итеп күрсәтелә. Мәсәлән, Авыргазы районы Нугазак авылы [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., 2021, б. 24–25] тарихын тасвирлаган риваятьтә, дин һәм тел аерымлыклары аркасында, татарларның дүрт чуваш гаиләсен авылдан куып җибәрүләре һәм чувашларга, яңа урында төпләнеп, Чуваш Нугазагы авылын нигезләргә туры килүе турында хәбәр ителә. Шушы ук мотив Дүртөйле районы Мәскәү авылы [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 37–38] тарихында да кабатлана. Биредә яшәүче татарлар һәм башкортлар 1914 елда күчеп килгән мариларны куып чыгарып, Олы Ялан авылына барып урнашырга мәҗбүр итә. Илеш районы Бәләкәй Бишкурай авылының [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., 2021, б. 40] барлыкка килүе исә риваятьтә тел мәсьәләсенә китереп тоташтырыла. Биредә Бишкурай авылы башкортларының типтәрләрне куып чыгарулары һәм яңа урынга күчеп утырырга мәҗбүр итүләре хакында хәбәр ителә.

Күренүенчә, дин һәм тел мәсьәләләре дә халык өчен гаять актуаль була. Динен һәм телен саклап калуны халык үзен саклап калуга тиңли, ят мәдәниятне, тормыш көтү рәвешен кабул итми, аны ничек тә үз мохитеннән кысрыклап чыгарырга омтыла.

Шулай итеп, авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә халык үзе кичергән вакыйгаларны традицион фольклор алымнарыннан файдаланып, сәнгатьчә гомумләштереп бирә. Шуңа күрә, тарихи риваятьләр татар халкының үткәнен, аның үз тарихын, дөньяга карашын, төрле чорлардагы эстетик идеалларын ачыклау өчен кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә.

---

[1] Татарстан Республикасының Мөслим районында – Мөслим, Лаеш районында Кабан исемле авыллар бар. *(И. Ф.)*

**Әдәбият**

Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.

Бөрбаш Сәрдегәне авылы тарихы // Бөрбаш. URL: https://borbash.life.tatar/2011/07/blog-post_8399.html (мөрәҗәгать итү датасы: 20.01.2023).

Гильом де Рубрук о реке Ягаке и о разных землях и народах в этой стране / Приложения. Источники по истории татар Западного Приуралья // История татар Западного Приуралья. Том I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства. Коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 343.

*Гыйләҗетдинов С.М.* Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 5–18.

*Еники Ә.* Соңгы китап. Истәлекләр. Казан: Татар.кит. нәшр., 1987. Б. 4–12.

*Миргалеев И.М., Аксанов А.В.* Введение // История татар Западного Приуралья. Том I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства. Коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2016. С. 6–7.

*Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. 232 с.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Россия төбәкләрендә татар фольклоры (И.К. Фазлетдиновның «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» (Уфа: Китап, 2018, 344 б.) китабына мөнәсәбәттә) // Фәнни Татарстан. 2019. № 1. Б. 160–170.

*Нәҙершина Ф.А.* Халыҡ хәтере (башҡорт халыҡ риүәйәт, легендаларының тарихи ерлеге, жанр үҙенсәлектәре). Тулыландырылған икенсе баҫма. Өфө: Ғилем, 2006. Б. 152–234.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Толстова Л.С.* Использование фольклора при изучении этногенеза и этнокультурных связей народов // Фольклор и историческая этнография. М., 1983. С. 6–21.

*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә мифологик мотивлар // Фәнни Татарстан. 2021. № 4. Б. 84–97.

*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының качкыннар һәм караклар турындагы риваятьләрендә тарих һәм мифология синтезы // Фәнни Татарстан. 2022. № 3. Б. 84–99.

*Фазлетдинов И.К.* Кереш // Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы

И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

*Фазлетдинов И.К.* Риваятьтә халык тарихы. Авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә XVI–XIX гасырлардагы миграция процессларының чагылышы: уку кулланмасы / фәнни редактор Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2003. 201 б.

*Фазлетдинов И.К.* Ришат Төхвәтуллин белән Газинур Морат авылдашлармы? // Кызыл таң. 2022. 21 октябрь.

*Фазлетдинов И.К.* Фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗановның фәнни һәм педагогик эшчәнлеге // Фәнни Татарстан. 2019. № 4. Б. 94–99.

*Фазлутдинов И.К.* Синтез исторических и мифологических воззрений в преданиях населения северо-западного Башкортостана // Славянские этносы, языки и культуры в современном мире: материалы VII Международной научно-практической конференции, посвященной 95-летию со дня рождения доктора филологических наук профессора Леонида Михайловича Васильева (г. Уфа, 23 сентября 2021 г.) / отв. ред. В.Л. Ибрагимова, Л.А. Киселева. Уфа: РИЦ БашГУ, 2021. С. 303–311.

*Фазлутдинов И.К.* Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.09. Уфа, 2005. 263 с.

***Фазлетдинов Илназ Илдус улы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты*
*Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникацияләр институтының*
*Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбе ассистенты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*аспиранты*